**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы**

БОЕРЫК

29.01.2013 ел Казан ш. № 02-7

**Финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан булып, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары һәм (яки) төрләре исемлеген һәм кодларын билгеләү тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 21 статьясындагы 4 пункты нигезендә, боерык бирәм:

1. Бу боерыкка кушымта нигезендә, Финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан булып, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары һәм (яки) төрләре исемлеген һәм кодларын билгеләү тәртибен расларга.

2. “2008 елның 1 гыйнварыннан финанс белән тәэмин итү субвенцияләр яки бюджетара субсидияләр хисабына хәл ителә торган җирле бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары һәм (яки) төрләре исемлеген һәм кодларын билгеләү тәртибен раслау турында” 28.12.2007 ел, № 02-122 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын (“Республика Татарстан”, 2008, 25 апрель) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет бүлегенә бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга җибәрергә.

Министр Р.Р. Гайзатуллин

Татарстан Республикасы Финанс
министрлыгының 29.01.2013 ел, № 02-7
боерыгы белән расланды

**Финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан булып, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары һәм (яки) төрләре исемлеген һәм кодларын билгеләү тәртибе**

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 21 статьясын тормышка ашыру максатыннан чыгып эшләнде, һәм ул финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан булып, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары һәм (яки) төрләре исемлеген һәм кодларын билгеләү механизмын билгели.

2. Чираттагы финанс елында һәм планда каралган чорда финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджетыннан булып, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар хисабына хәл ителә торган бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары һәм (яки) төрләре исемлеге һәм кодлары чираттагы финанс елына һәм планда каралган чорга Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы нигезендә расланган чыгымнарның максатчан статьялары һәм (яки) төрләре исемлеге һәм кодлары нигезендә булдырыла.

3. Максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләрнең, субвенцияләрнең һәм башка бюджетара трансфертларның һәр төренә максатчан статья коды бирелә. Максатчан статья коды чыгымнар классификациясенең 20 урынлы кодының 8-14 разрядлары буенча – җиде урынлы билгедән тора.

4. Җирле бюджетларны раслауда һәм үтәүдә, шулай ук средстволарны муниципаль районнар бюджетларыннан җирлекләр бюджетларына тапшырганда, җирле үзидарә органнары, максатчан билгеләнешкә ия булган бюджетара субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бирү өчен, Татарстан Республикасы бюджетындагы максатчан статьялар кодларының дәвамчылыгын тәэмин итә.